КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 июль г.Казань № 616

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 30 май, 443 нче; 2012 ел, 25 июль, 630 нчы; 2012 ел, 6 ноябрь, 969 нчы; 2013 ел, 7 март, 154 нче; 2014 ел, 16 май, 326 нчы; 2014 ел, 11 август, 580 нче; 2015 ел, 28 май, 386 нчы; 2016 ел, 26 февраль, 120 нче; 2016 ел, 19 сентябрь, 656 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 361 нче; 2017 ел, 11 декабрь, 972 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1114 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 865 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1144 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1190 нчы; 2019 ел, 23 май, 433 нче; 2020 ел, 4 февраль, 74 нче; 2020 ел, 14 февраль, 109 нчы; 2020 ел, 12 ноябрь, 1016 нчы; 2021 ел, 28 гыйнвар, 34 нче; 2021 ел, 13 август, 711 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.1.113 һәм 4.1.114 пунктчаларны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«4.1.113. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гидроэлектростанцияләрдә электр энергиясен җитештерү максатларында файдалануга бирелгән су объектларыннан файдалануны килештерүдә катнаша.

4.1.114. Электр энергетикасы объектларының техник-икътисадый торышы күрсәткечләре (башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органнары тарафыннан техник торышы контрольдә тотыла торган электр энергетикасы объектларыннан тыш), шул исәптән электр челтәре хуҗалыгы объектларының физик тузу һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мониторингын гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин